ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛЫНДА ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

2021 нче елның 20 нче декабрендәге 6 нчы номерлы КАРАРЫ

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Татар Чаллысы авылы гражданнарының җыены нигезендә

карар итте

1. 2022 елда Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Татар Чаллысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**1. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, үлән чабу, балалар мәйданчыгын киртәләү өчен материал сатып алу.)**

**2. Урамнарны яктырту өчен яктырткычлар урнаштыру**

**3. Бензин белән эшләүче кар чистарткыч сатып алу**

**3.** Узган еллардагы акча калдыкларын җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен файдаланырга: авыл җирлеге территориясен төзекләндерү буенча эш башкарырга

4. Халык җыены нәтиҗәләрен Татар Чаллысы авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.